**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1913**
**08.04.2022**

Башкарма комитетның 2022 елның 24 гыйнварындагы 243 номерлы карары белән расланган Муниципаль торак фондының торак урыннарын гражданнар милкенә тапшырганда документлар рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясенең «Россия Федерациясендә торак фондын приватизацияләү турында» 1991 елның 4 июлендәге 1541-1 номерлы Законы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2022 елның 24 гыйнварындагы 243 номерлы карары белән расланган муниципаль торак фондының торак урыннарын гражданнар милкенә тапшырганда документлар рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5.1. Муниципаль хезмәттән файдалану өчен гариза бирүче түбәндәге документларны тапшыра:

1) шәхесне раслаучы документ (Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә таләп ителми);

2) гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ;

3) гариза:

- кәгазь документ формасында (административ регламентка 3 нче кушымта);

- Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, административ регламентның 2.5.3 пункты таләпләре нигезендә имзаланган электрон формада

(гаризаның электрон формасына тиешле мәгълүматларны кертү юлы белән тутырыла);

4) гаиләнең һәр әгъзасының шәхесен раслаучы документлар;

5) күчемсез милек объектының техник паспорты;

6) йорт кенәгәсеннән архив өземтәсе яисә приватизацияләнүче торак урында теркәлгән, шулай ук теркәлү исәбеннән төшерелгән, әмма торак урыннан файдалану хокукын югалтмаган барлык Россия Федерациясе гражданнары турында мәгълүматны үз эченә алган башка шундый ук документ;

7) йорт кенәгәсеннән архив өземтәсе яки яшәү урыныннан белешмә, яшәү урыны һәм (яки) тору урыны буенча теркәлү турында таныклык, 1991 елның 11 июленнән башлап элекке даими яшәү урыннары турында адреслы белешмәләр яисә Россия Федерациясе гражданы паспортының яшәү урыны буенча, шул исәптән 1991 елның 11 июленнән башлап элекке яшәү урыннары буенча теркәлү турында мәгълүматны үз эченә алган битләренең күчермәләре, торак урынны приватизацияләүдә катнашучы барлык Россия Федерациясе гражданнарына;

8) приватизацияләүдә катнашудан баш тарту турында нотариаль таныкланган гариза (әгәр гаилә әгъзалары приватизацияләүдә катнашырга теләмәсә).»;

2) 2.6 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 6, 7, 8, 9 пунктчалар өстәргә:

«6) гражданнарның торак урыннан файдалану хокукын раслый торган документ (торак урынның ордеры, социаль наем шартнамәсе);

7) әгәр торак урында бары тик 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган яисә хокукка сәләте чикләнгән гражданнар яшәсә, опека билгеләүне раслаучы документ – опека һәм попечительлек органнары;

8) опека һәм попечительлек органнарының торак урынны приватизацияләүгә рөхсәте – бары тик 14 яшькә кадәрге балигъ булмаган, хокукка сәләтсез гражданнар яшәгән торак урынны приватизацияләгәндә – опека һәм попечительлек органнары;

9) элекке яшәү урыннарыннан түләүсез приватизацияләү хокукыннан файдаланмау турында мәгълүматлар.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары А.С. Ганиевка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев